РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МЕНДЕЛЕЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН ГЛАВА КАМАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
423643 с.Камаево, ул. Дифгата
Сирая д.29А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
423643, Камай авылы, Дифгать Сирай
урамы, 29А йорты

Тел. (885549)3-55-33

2025 елның 7 нче ноябреннән № 4

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлегенең Камай авылында
2026 елга гражданнарның үзара салымын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьялары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 20 ноябрендә 16 сәгать 30 минутка Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2025 елның 20 ноябрендә 17 сәгать 30 минутка Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегенә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Җыеннарның барлык этапларын үткәрү урыны итеп Камай авылы КФҮ ген (авыл мәдәният йорты) түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Камай авылы, Дифгат Сирая урамы, 29а.
4. Камай авылында яшәүчеләр исемлеген җыеннар этапларына бүлүне территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга :

1.Беренче этап: Яшел урамының 1нче йорттан 25нче номерлы йортка кадәр;Тынычлык урамының 3нче йорттан 24нче йортка кадәр; Дифгат Сирая урамының 1нче йорттан 49нчы йортка кадәр, газовиклар урамы 3 нче йорт.

2. Икенче этап: Тынычлык урамының 25 нчедән 81нче номерлы йортлары; Сәйдәш урамының 1нчедән 18 нче номерлы йортлары; Төньяк урамының, 1нчедән 16 нчы номерлы йортлары.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Камай авыл җирлегенең Камай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, мобилизацияләнгән гражданнардан башка, 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту);
2. Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу, МАФ сатып алу, МТЗ-82.1 тракторы өчен чүмечле КУН сатып алу; МТЗ-82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу);
3. Урамнарны яктырту электр челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү (тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау)?

« ӘЙЕ» «ЮК».

6. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтының www.mendeleevsk.tatar.ru «Камай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

7. Бу карар бастырылган көннән үз көченә керә.

Камай авыл җирлеге башлыгы И.М.Ахунҗанов